ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.4, д. Канаш,
422584

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 4 нче йорт, Канаш авылы,
422584

Тел.: (84379) 36-7-45, факс: (84379) 36-7-45.

26.11.2019 №3-1

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 6 ноябрендә «2020 елда һәр балигъ булган кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында юлларга вак таш җәю

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 12 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 6 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында узган халык җыенын узмаган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес түгел дип таныргa.

2. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Канаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен юнәлтергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Н.Н. Вальков